**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы**
**Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

№ 4 Бәйрәкәтамак ав. 04 март 2016 ел

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2016 елның 28 февралендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында»гы 14 санлы карарын теркәү турында.

2002 елның 12 июнендәге «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында»гы 67-ФЗ санлы Федераль законның 73 маддәсендәге 5 пункты, 2004 елның 24 мартындагы «Җирле референдум турында"гы 23-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законының 60 маддәсендәге 3 пункты нигезендә, Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2016 елның 28 февралендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында»гы 14 санлы карарын теркәргә.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Бәйрәкә-Тамак авылы, Яңа урам, 37 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында бастырырга һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга. http://jutaza.tatarstan.ru.

Бәйрәкәтамак авыл җирлеге
авыл җирлеге башлыгы З. М. Әһлиева